**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**31.01.2018** **№ 311**

**2019 елга «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы «Татарстан Республикасы балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2018 елга түбәндәгеләрне кушымта нигезендә расларга:

- «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгати-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарын;

- балаларга сәнгати-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы МКУнә «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы

башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе                                        И.Ф. Хөснетдинов

Кушымта

ТР Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның
31 гыйнварындагы 311 номерлы
карары белән расланды

**«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгати-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (1 укучыга елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри юнәлеш |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 55 683 | 64 454 | 83 712 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 30 640 | | 26 713 | 64 146 |
| Хореографик сәнгать | авыл җирлеге | | | 58 850 | 48 526 | 177 088 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 25 637 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 55 306 | 53 072 | 85 850 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 84 935 | | 81 297 | | 134 154 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 43 880 | | 40 750 | 40 748 | 64 149 |